**Әламнең данлы юлы.**

22 август көнне Бәзәкә авыл китапханәсендә Россиянең Дәүләт флагы көне уңаеннан укучылар өчен “Әламнең данлы юлы” дигән танып белү сәгате үткәрелде. Чарада китапханәче Ф.Башарова Дәүләт символлары белән таныштырды, Россия әламе үткән данлы юл турында сөйләде, “Ватаныбыз турында” дигән китап киштәсендәге китапларны тәкъдим итте. Аннары бергәләп Дәүләт бәйрәмнәрен искә төшерделәр.  Чара ахырында “ООО “Колхоз Кама”  директоры Р.Садриев  беренче сыйныфка укырга баручы балаларга “Помоги собраться в школу” акциясе кысаларында ранецлар тапшырды һәм укуларында уңышлар теләде.




Россиянең
Хәтер
йөрәкләрдә яшәсен!



